РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 апрель 2023ел № 172

**Әтнә муниципаль районы Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты турында»гы 2022 елның 15 декабрендәге 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Әтнә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиев докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Әтнә район Советы карар чыгарды:

1). 1нче, 3нче, 4нче һәм 8нче статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 Статья

1. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган гомуми керем күләме 562551,1 мең сум.;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 569627,6 мең сум.;

в) Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгы 7076,5 мең сум.

2. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3 Статья

Әтнә муниципаль районы бюджетында Әтнә муниципаль районының 2023 елга бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья

1. Әтнә муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Әтнә муниципаль районының бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, 2023 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча әлеге Карарга 3 нчы кушымта нигезендә бүлүне расларга.

2. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әтнә муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Әтнә муниципаль районының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), 2023 елга бюджет чыгымнары

классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре бүлекләре, бүлекчәләре, буенча әлеге Карарга 3 нчы кушымта нигезендә бүлүне расларга.

8 Статья

Әтнә муниципаль районы бюджетында 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертларны, 9 нче кушымта нигезендә бүленеп, үзгәртергә.»

2). Әтнә районы Башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарларын расларга:

06.02.2023ел №82; 10.03.2023ел № 182.

3). Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов